**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.п. № 47 "15" октябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының 2017 елның 13 ноябрендәге 23 номерлы карары белән расланган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен өченче зат (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан ирекле муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибенең 1.7 пунктының үз көчен югалтуын тану турында

«Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне киңәйтү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 пунктының «б» пунктчасы нигезендә

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының 2017 елның 13 ноябрендәге 23 номерлы карары белән расланган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен өченче зат (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан ирекле муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибенең 1.7 пунктының үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Р.А. Галиева